КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 22 декабрь | г.Казань | № 1671

2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 22 декабрь, 1617 нче
карары белән расланды

2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – Фонд, субсидия) бирү механизмы билгеләнә.

2. Субсидия 2023 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидия Фондның субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның1 енче көненә түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

Фондның салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәсе булмау;

Фонд үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функцияләрен үтәүче зат яки Фондның баш бухгалтеры турында белешмә булмау;

Фонд чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Фонд әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый.

5. Субсидия күләме Фондның бирелгән финанс планы нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2023 елда Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы буларак билгеләнә.

6. Субсидия Министрлык һәм Фонд арасында төзелгән килешү нигезендә бирелә. Килешү Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре, субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсе зурлыгына ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә

ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, шулай ук өстәмә хисап бирү сроклары, тәртибе һәм формасы (кирәк булганда);

Фондның, Фонд белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

Фонд тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр;

Фонд, шулай ук Фонд белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шарт;

элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган итеп киметкән очракта яки яңа шартлар белән килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт, килешүнең яңа шартларын килештерү тәртибе;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан әлеге акчага ихтыяҗ булу яки аларга ихтыяҗ булмаганда әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында карар бу Тәртипнең 20 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кабул ителгәндә финанслар белән тәэмин итү чыганагы 2023 елда субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге хакында шарт.

Министрлык белән Фонд, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

6. Субсидия алу өчен Фонд Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Тәртипнең 1 кушымтасында бирелгән форма буенча Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан кул куелган, түбәндәге документлар теркәлгән заявка:

финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чыгымнары Фонд тарафыннан гамәлгә ашырылуны чагылдырыла торган, ишегалды территорияләре күрсәтелгән, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән Фондның финанс планы;

Фондның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган белешмә кәгазе;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре;

Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре.

Документлар кәгазьдә һәм (яки) электрон чыганакларда бирелергә мөмкин.

Кәгазьдә бирелгән барлык документлар төгәл бастырылырга тиеш. Бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр ясау, Фондның мөһере сугылган һәм җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) имзасы белән расланган төзәтүләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазьдә тапшырылган заявкаларның барлык битләре тегелгән, номерланган, Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзасы белән расланган булырга тиеш.

Әлеге пунктта һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең һәм тапшырылган документларның дөреслеге өчен Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Фонд, заявка белән бергә, үз теләгенә карап, түбәндәге документларны Министрлыкка тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә;

салым органында исәпкә кую турында документ күчермәсен;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1нче көненә салым органы тарафыннан салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында бирелгән белешмә кәгазе.

Фонд тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмат алышу тәртибендә соратып ала.

Министрлык заявканы теркәлгән документлары белән кабул итүне һәм кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

Министрлык заявканың әлеге Тәртипнең 7 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен, Фондның әлеге Тәртипнең 4 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм заявка кергән көннән алып 10 календарь көннән артмаган срокта субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында Фондка хәбәр итә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Фонд тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Фонд тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

11. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында Фонд ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

12. Субсидия бирү нәтиҗәсе – 2024 елның 31 декабренә карата Татарстан Республикасының 32 муниципаль берәмлегендә кимендә 764 ишегалды территория-сен төзекләндерү эшләрен башкару.

13. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп киметелгән очракта, Министрлык бирелә торган субсидия күләмен үзгәртү турында карар кабул итә һәм Фондка килешүгә үзгәреш кертү кирәклеге турында хәбәр итә.

14. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәге чыгымнар керә:

ишегалды территорияләрен төзекләндерү объектларының проект-смета документациясен эшләү;

ишегалды территорияләрен төзекләндергәндә юл эшләрен башкару;

ишегалды территорияләрен төзекләндергәндә урам яктырткычларын урнаштыру;

ишегалды территорияләрен төзекләндергәндә кече архитектура формаларын урнаштыру.

15. Субсидия Фонд тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

Фонд тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча да – тулы күләмдә;

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгына ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап билгеләнгән срокларда тапшырылмаган очракта – тулы күләмдә;

Фонд тарафыннан килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгына ирешелмәү факты билгеләнгәндә – килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсеннән читкә тайпылган исәпләү зурлыгына пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә.

16. Килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгына ирешелмәгән очракта, кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) (сумда) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{\text{кире кайтару}} = V_{\text{субсидия}} \times k,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидияне кире кайтару коэффициенты.

Субсидияне кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән исәпләү зурлыгы;

S – килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча исәпләү зурлыгы.

17. Фонд квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгына ирешү турында һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра.

18. Фонд субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

19. Министрлык Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Акчаның финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган, 2023 елда файдаланылмый калган өлеше, 2024 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында Министрлык тарафыннан карар кабул ителгән очраклардан тыш) кире кайтарылырга тиеш.

2023 елда файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, Фонд, 2024 елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, Фондтан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алынган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидиянең 2023 елда файдаланылмый калган өлешен 2024 елда җибәрүгә ихтыяҗ булу турында яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан субсидиянең 2023 елда файдаланылмый калган өлешен 2024 елда җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта,

Министрлык белән Фонд арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

21. Фонд тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 һәм 20 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә аларны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

22. Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларга ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрелә.

23. Бирелә торган субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

____________________________________________

(тулысынча) Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды (алга таба – Фонд) җитәкчесе (аның вазифаларын башкаручы зат)

____________________________________________

__________________________________(дан, нан)

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә
заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 22 декабрь, 1671 нче карары белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен

________________________________________________________________________________________

(Фонд исеме)

________________________ (______________________________________) сум ___ тиен күләмендә

(суммасы саннар белән) (суммасы сүзләр белән)

субсидия бирүегезне сорыйм

Бу заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмә һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмә һәм документлар тапшыру, субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозу ачыкланган очракларда, бирелгән субсидия Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарырга бурычлы булуым турында хәбәр ителде.

_____________________________________________________________ның (нең)
(Фонд исеме)

субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енче көненә түбәндәгеләргә ия булуын раслыйм:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмавын;

үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында Фондның дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функцияләрен үтәүче зат яки Фондның баш бухгалтеры турында белешмә булмавын;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын.

________________________________________________________________ карата
(Фондның исеме)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризамын.

Фонд җитәкчесе
(аның вазыйфаларын башкаручы зат) __________/ _______________________________________/
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.

Дата: 20__ ел, «__» __________

_______________________

2023 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондының финанс планы

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Объектның адресы һәм исеме | Каты өслекләр мәйданы, кв.метр | Юл эшләрен башкару кыйммәте, сум | Кече архитектура формаларын урнаштыру кыйммәте, сум | Урам яктырткычлары җайланмасы кыйммәте, сум | Гомуми кыйммәте, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барысы бергә, шул исәптән: | | | | | | |
| | проект-смета документациясен эшләү кыйммәте | | | | | | |
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| … | | | | | | | |

Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат)

_____________/ _____________________________________________/
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.

Дата: 20__ ел, «__» ________

Килештерелде
Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондын гамәлгә куючы

_________/ __________________________________________/
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.

Дата: 20__ ел, «__» ________

_______________________________________________________